Китап күңел үстерә

# Балачак иленә тугрылык



Моннан 33 ел элек - балалар үлчәмендә борын-борын заманда - яшь автор Рәшит Бәшәровның “Әйлән-бәйлән” дигән беренче китабы дөнья күргәч тә, шагыйрә Саҗидә Сөләйманова: “Рәшит Бәшәровның көчле ягы - әйләнә-тирәне рәссамча күрә, табигатькә җан өрә белүендә. Һәм бигрәк тә балалар күңелен аңлый, дөньяга алар күзе белән карый белүендә”, - дип язып чыккан булган. Бүген дә, Рәшит абый Бәшәрнең инде унберенче китабын - “Мәгариф” нәшриятендә дөнья күргән “Җәй кызы”н кулга алгач та, сөекле шагыйрәбезнең нәкъ шушы ук сүзләрен кабатлыйсы килә.

Булса да булыр икән балачак иленә тугрылык! Асылда һәрберебезгә үзәк өзгеч якын, газиз булган бу тылсымлы илдә, ни кызганыч, без инде бик сирәк кунак. Ә менә Рәшит абыйның аннан киткәне дә юк. Һаман да сабый күңеле белән дөньяны балаларча тоеп, кабул итеп, балаларча елап-көлеп, уйнап, мәш килеп яшәп ята. Иң сөендергәне - уй-хисләрен шигырь юлларына күчерергә дә, хикәя-повесть итеп язарга да онытмый үзе. Телләрне йотарлык итеп тәмләп, ышандырып, сокландырып яза.

Аның “яңа гына табадан төшкән” дигән әйтемгә бик тә туры килеп торган, кып-кызыл тышлы, олы форматлы “Җәй кызы” китабы исеме белән дә, җисеме белән дә очлы күз бала-чаганы гына түгел, аларның әти-әниләрен, әби-бабаларын да үзенә җәлеп итәрлек. Дөрес, мине башта тышлыкның кызыл төстә булуы бераз гаҗәпләндергән иде. Җәй фасылы яшел, һичьюгы, аллы-гөлле чәчәкле булырга тиеш бит инде, югыйсә. Бераздан гына, кем әйтмешли, барып җитте. Җәйнең үзе түгел, ә аның кайнар кояш нурларында кызарган, җиләктәй алланып пешкән, ялкын телләредәй җирән чәчле кызы турында ич бу китап! Шуңа да кызылдыр...

Хәер, кыздан башка да китапның персонажлары бик күп. Ап-ак Ат, Әрлән, Бал кортлары, аларның Ватаны - киң болын, Давыл чәчәге, Еланнар.... Туктыйммы санаудан? Әйе, төшенгәнсездер, шагыйрь Рәшит Бәшәр бу юлы гаҗәеп матур, үзенчәлекле шигъри әлифба төзергә уйлаган. Аның үзенчәлеге шунда, әлеге әлифба аерым кыска шигырьләрдән генә тормыйча, мавыктыргыч, искиткеч гүзәл сюжетлы, укыган саен укыйсы килеп торган озын бербөтен әсәрдән гыйбарәт.

*Ат йомшак иренен*
*Тидерде дә солыга,*
*Ашап туйгач, баш чөеп,*
*Чыгып чапты болынга, -*

дип башланып китә ул. Иманым камил, бу китапны кулына алган һәрбер бала әлеге атка, җәй кызына ияреп болынга чыгып китәчәк. Һәм чәчәкләр җыеп, күлдә йөзеп, яңгырда коенып, “бал корты канатына тамган тамчы тавышы”на кадәр ишетеп, рәхәтләнү белән бергә, туган телебезнең ямен, тәмен, хуш исен тоеп та ләззәтләнәчәк. Мәсәлән, түбәндәге юлларны укыганда:

*...Тамчылар*
*Коела да коела.*
*Рәхәтләнеп, таралып,*
*Табигать су коена...*

Яисә боларын:

*...Күперен калды болын,*
*Һавадан алсу нурлар*
*Сузылды толым-толым...*

Менә шундый, телебезгә, табигатькә мәхәббәт тойгысы уята торган бербөтен әсәр. Милләтнең киләчәге булган һәр сабыйны әлеге хис-тойгы гомере буе озата барсын иде, дигән изге теләк, максат белән иҗат итүче шагыйрь Рәшит Бәшәргә бу күңел бүләге өчен чын йөрәктән рәхмәт әйтәсе генә кала. Билгеле, аның һаман саен серле балачак иленнән безгә китапсәламнәр җибәреп торуын да сорарга онытмыйча.

**Сирень ЯКУПОВА.**
Чаллы.